| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының авыр йөкле йөкләрне автомобиль белән ташуга, муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча эре габаритлы йөкләр бирүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010нчы елның 27нче июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010нчы елның 2нче ноябрендәге 880нче номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә расларга:

Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча авыр йөк ташуга, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты 1нче кушымта һәм «Авыр йөкләрне, муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә узучы маршрутлар буенча эре габаритлы йөкләрне автомобиль йөртүгә рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы 2 нче кушымта.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» №865 от 30.06.2016 ел карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Ресоның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Әзерләде һәм бастырды:
Московкин А.А. 4 экз.